| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|
| КАРАР | ПОСТАНОВЛЕНИЕ |
| № 96 | «08» 10 2020 ел |

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитетына һәм «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибен раслау турында

"Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитетында һәм «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау буенча бердәм тәртип урнаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитетына һәм «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенә кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http:/ www.spassriy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

ТР Спас муниципаль районының
Болгар шәһәр башкарма комитеты
җитәкчесе вазифаларын башкаручы — И.А. Кузнецов

БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

Спас муниципаль районы Болгар шәһәр
Башкарма комитеты
№ 96 «08» 10 2020елның
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр Башкарма комитетына һәм «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенә гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе.**

1. Әлеге тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм гражданнарның Болгар шәһәр башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Болгар шәһәре” муниципаль берәмлегенә килгән мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Болгар шәһәр Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә Анализ ясау гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә Анализ тиешле чорга кергән барлык мөрәҗәгатьләр, шул исәптән язма рәвештә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү аша җибәрелгән электрон документ рәвешендә, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ ел саен башкарыла.

5. Хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш (булганда).

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә Анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты белгече ел саен аналитик белешмә Спас муниципаль районы «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.